АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

**РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА** **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 30.05.2019 № ПР-134-2

г. Казань

**Торак пунктларның һәм территориаль зоналарның чикләрен билгеләү һәм муниципаль берәмлекләрне социаль-икътисади үстерү программалары нигезендә әлеге документларга үзгәрешләр кертү өлешендә территориаль планлаштыру документларына закон таләпләрен гамәлгә ашыру буенча эшләрнең барышы турында**

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры урынбасары В.Н.Кудряшев мәгълүматын тыңлап һәм тикшереп, “Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы” (алга таба – Совет) Ассоциациясе президиумы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры урынбасары В.Н.Кудряшев мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына “Татарстан Республикасы кыңлекләр белешмәләре фонды” ГБУ белән берлектә торак пунктларның һәм территориаль зоналарның чикләрен ЕГРНга исәпкә куюны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына 2019 елның 1 августына кадәр вакытта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелеше зоналаштыру документларын “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү буенча эшләрне этаплап финанслау күләмнәре турында тәкъдимнәр әзерләргә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгына 2019 елның 1 июленә кадәр вакытта, Татарстан Республикасы җирле үзидарә

органнарына аннары җибәрү өчен, территориаль планлаштыру документларын раслау тәртибе турында тәкъдимнәр әзерләргә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына:

- территориаль планлаштыру документлары кабул иткәндә һәм раслаганда югарыда күрсәтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алырга;

-Совет президиумының 2019 елның 27 февралендәге ПР-124-2 номерлы карарының 3.2 пункты нигезендә территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелеше зоналаштыру документларын эшләгәндә һәм аларга үзгәрешләр керткәндә, әлеге документларны тиешле муниципаль районнар җирле үзидарә органнары тарафыннан раслау өлешендә "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нормаларын үтәүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны үтәүгә контрольне Советның башкарма секретаре А.Г.Барышевка йөкләргә.

**Рәис** **Ә.С.Гобәйдуллин**